РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ ГОРОДСКОЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

***Постановление*** ***Карар***

**2019 елның 18 декабре** **Чистай шәһәре** **№ 245**

Чистай муниципаль районы
шәһәр Башкарма комитетының
2017 елның 25 гыйнварындагы
13 номерлы карары белән расланган
«Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге
территориясендә муниципаль урман
контролен гамәлгә ашырганда
тикшерүләр үткәрүнең административ
регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Чистай шәһәр прокурорының 2019 елның 10 декабрендәге 02-08-02-2019 номерлы протестын үтәү йөзеннән, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында»гы 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон белән, «Россия Федерациясендә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре турында»гы 2014 елның 29 декабрендәге 473-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында"гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Чистай шәһәре Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чистай муниципаль районы шәһәре Башкарма комитетының 2017 елның 25 гыйнварындагы 13 номерлы карары белән расланган «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль урман контролен гамәлгә ашырганда тикшерүләр үткәрүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. I бүлекне тулыландырырга. 1.7.1 пункты белән Гомуми нигезләмәләрне тулыландырырга.

«1.7.1. Чистай шәһәренең алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территоиясендә (алга таба – ТОСЭР) Чистай шәһәренең алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентларына карата (алга таба – ТОСЭР резидентлары) муниципаль урман контроле әлеге Регламент нигезендә һәм «Россия Федерациясендә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре турында» 2014 елның 29 декабрендәге 473-ФЗ номерлы Федераль законның 24 статьясында билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып, муниципаль урман контроле органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (http://chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Ф.М. Садыйковка йөкләргә.

Шәһәр Башкарма комитет
җитәкчесе И.Ф.Рәхимов